Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Тураевская средняя общеобразовательная школа»
Менделеевского муниципального района Республики Татарстан

# Рабочая программа
# по родной литературе (татарской)

***для общеобразовательных организаций с обучением на татарском языке***

Уровень образования: среднее общее образование, 10-11 классы

Разработано: ШМО учителей русского языка и литературы,
родного языка и литературы , иностранных языков

Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы
Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
“Турай урта гомуми белем бирү мәктәбе”

***Татар телендә белем бирү оешмалары өчен***
**әдәбияттан (татар әдәбиятыннан) эш программасы**

Белем дәрәҗәсе(сыйныф): урта гомуми белем, 10-11 нче сыйныфлар

Эшләнгән:рус теле һәм әдәбияты, туган тел һәм әдәбият,чит телләр укытучыларының ММБ

10-11 нче сыйныфта әдәбияттан (татар әдәбиятыннан) эш программасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән программага Татар телендә урта белем бирү мәктәпләре (10-11 нчы сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа. Төзүче-авторлары: Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова. Казан, 2013, нигезләнеп төзелде.

**Дәреслекләр:**

| Сыйныф | Дәреслекләр авторы | Нәшрият |
|---|---|---|
| 10 | Ф.Ә.Ганиева, Д.М.Абдуллина, Ч.Р.Рамазанова | Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2016, ике кисәктә |
| 11 | Ф.Ә.Ганиева, Д.М.Абдуллина, Ч.Р.Рамазанова | Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2017, ике кисәктә |

Барлыгы: **69** сәгатькә исәпләнгән (10 сыйныф-35 сәг, 11 сыйныф -34 сәг)

## Укучыларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә таләпләр
## 10 сыйныф

Татар әдәбияты предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучы:

- милли әдәбиятның иң билгеле язучыларын һәм аларның әсәрләре хакында;
- милли әдәбиятның нинди чорларга бүленешен;
- сүз сәнгатенең образлы асылын;
- әдәби-тарихи барышның төп закончалыкларын һәм әдәби юнәлеш, күренешләрнең төп сыйфатларын;
- төр әдәби-теоретик төшенчәләрне белерг;
- әдәби әсәр эчтәлеген кабатлап сөйләү;
- әдәби әсәрне әдәбият тарихыннан һәм теориясеннән мәгълүматлар файдаланып анализлау;
- әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының аерым якларын, элементларын җентекләп тикшерү һәм нәтиҗәләр чыгару;
- әдәби әсәрне, язучы иҗатын, чор әдәбиятын иҗтимагый-тарихи контекстта һәм гомумкешелек кыйммәтләре яктылыгында бәяләү;
- әдәби әсәрнең төр һәм жанрын, кайсы чорда язылуын билгеләү, чор әдәбиятына хас сыйфатларны табу;

- бер чорда иҗат ителгән һәм төрле чорларда иҗат ителгән әдәби әсәрләрне чагыштыру;
- әдәби әсәргә карата дәлилле шәхсән мөнәсәбәт белдерә алу;
- әдәби әсәрләр хакында төрле характердагы иҗади эшләр башкару күнекмәләрен үзләштергән булырга тиеш.

- **рецептив эшчәнлек буенча**: сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлы, иҗаты, чор әдәбияты турында чагыштырып, бәяләп, яттан өзекләр китереп сөйләү; әдәби әсәрнең төрен, жанрын, язучы иҗатының төп хасиятләрен, чор әдәбиятының төп үсеш юнәлешләрен билгеләү һәм фикерне исбатлау; әдәби әсәрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә аңлау; әдәби әсәрләрнең тарихи-конкрет һәм гомумкешелек кыйммәтләрен, әдәбияттагы «үтәли» һәм «мәңгелек» проблемаларны ачыклый алу күнекмәләре формалашкан булу.
- **репродуктив эшчәнлек буенча**: әдәби әсәрнең сюжетын, анда сурәтләнгән вакыйгаларны, характерларны аңлатып бирә, башка әсәрләр белән чагыштыра, бәяли алу; чор әдәбиятына кагылышлы мәгълүматларны гомумиләштереп сөйли алу; төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар) белән максатчан эшли белү; вакытлы матбугат материалларына мөрәҗәгать итә алу күнекмәләре формалашкан булу.
- **иҗади эшчәнлек буенча**: төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади, сәнгатьле укый белү; әдәби әсәрләр, язучы иҗаты, чор әдәбияты, гомумән милли әдәбият буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение яза алу;
- **эзләнү эшчәнлеге буенча**: әдәби әсәргә, язучы иҗатына, чор әдәбиятына, милли әдәбияттагы аерым күренешләргә нисбәтле проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; әсәр белән башка текстлар, шул исәптән башка сәнгать төрләре арасында ассоциатив бәйләнешләрне күрә алу;
- **тикшеренү эшчәнлеге буенча**: тулы текстны анализлау; төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү; әсәрләрне үзара чагыштыру, уртак һәм аермалы якларны таба белү; язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белү; татар, рус (яки башка халыкларның) әдәбиятларында бер төрдәге темага язылган әсәрләрне чагыштыру, милли үзенчәлекләрен ачыклау; татар әдәбиятының рус һәм дөнья әдәбияты мәйданындагы урынын һәм ролен бәяләргә омтылу.

*Танып-белү өлкәсендә*:

- аерым чорларда иҗат ителгән әсәрләрне форма һәм эчтәлек берлеге төсендә кабул итәргә өйрәтү, сайлап уку ихтыяҗы булдыру һәм әсәргә салынган мәңгелек кыйммәтләрне билгеләргә күнектерү;
- укыган әдәби әсәрнең үзе иҗат ителгән чор белән тарихи-мәдәни бәйләнешләрен аңлавына ирешү;
- укучының классик әдипләр тормыш һәм иҗат юлын, милли әдәби барышның төп этапларына хас үзенчәлекләрне һәм билгеләрне белүе;
- рефератлар, докладлар әзерләргә, әдәби әсәрләр һәм ирекле темалар буенча сочинениеләр яза алу, иҗади эшләр башкара алу;
- әдәбият тарихын тикшергән вакытта әдәбият белеме төшенчәләренә мөрәҗәгать итәргә өйрәтү.

*бәяләү өлкәсендә*:
- милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңелдән уздырып кабул итәргә өйрәтү;
- милли әдәбиятка, андагы күренешләргә шәхси мөнәсәбәт һәм бәя формалашу, әсәргә, язучы иҗатына, чор әдәбиятына бәйле телдән һәм язмача фикерләрне белдерә алу;
- өйрәнелгән әсәрләрне чор әдәбияты фонында шәрехли белүе;
- автор осталыгын бәяли алу һәм аңа карата мөнәсәбәт формалашкан булу.
- татар әдәбиятын рус әдәбияты белән бәйләп, тема һәм проблематикада, геройлар бирелешендә, иҗат юнәлешләрендә, чор әдәбиятларында уртаклыкларны таба белүе.

*эстетик яктан*:
- сүз сәнгатенең образлы табигате хакында гомуми мәгълүматый күзаллау булу, эстетик зәвык формалашу;
- төрле мәдәни дөньяларның, милли әдәбиятларның казанышларына игътибарлы һәм ихтирамлы караш формалашкан булу.
- әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре ярдәмендә мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булу һәм әдәбият–сәнгать белән даими кызыксыну формалашу;
- татар теленә бәйләнештә, туган телдә аралашырга ихтыяҗ булу;
- укучыда мәдәниятара бәйләнешләрне саклау ихтыяҗы булу, башка милләтләр мәдәнияте һәм әдәбиятыннан мәгълүматлы булуы, башка халыкларның сүз сәнгатенә хөрмәтле мөнәсәбәттә, толерант булуына ирешү;

## 11 сыйныф

.

Татар әдәбияты предметын үзләштерү нәтиҗәсендә укучы:
- милли әдәбиятның иң билгеле язучыларын һәм аларның әсәрләре хакында;
- милли әдәбиятның нинди чорларга бүленешен;
- сүз сәнгатенең образлы асылын;
- әдәби-тарихи барышның төп закончалыкларын һәм әдәби юнәлеш, күренешләрнең төп сыйфатларын;
- төр әдәби-теоретик төшенчәләрне белергә;
- әдәби әсәр эчтәлеген кабатлап сөйләү;
- әдәби әсәрне әдәбият тарихыннан һәм теориясеннән мәгълүматлар файдаланып анализлау;
- әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының аерым якларын, элементларын җентекләп тикшерү һәм нәтиҗәләр чыгару;
- әдәби әсәрне, язучы иҗатын, чор әдәбиятын иҗтимагый-тарихи контекстта һәм гомумкешелек кыйммәтләре яктылыгында бәяләү;

- әдәби әсәрнең төр һәм жанрын, кайсы чорда язылуын билгеләү, чор әдәбиятына хас сыйфатларны табу;
- бер чорда иҗат ителгән һәм төрле чорларда иҗат ителгән әдәби әсәрләрне чагыштыру;
- әдәби әсәргә карата дәлилле шәхсән мөнәсәбәт белдерә алу;
- әдәби әсәрләр хакында төрле характердагы иҗади эшләр башкару күнекмәләрен үзләштергән булырга тиеш.

- **рецептив эшчәнлек**: сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлы, иҗаты, чор әдәбияты турында чагыштырып, бәяләп, яттан өзекләр китереп сөйләү; әдәби әсәрнең төрен, жанрын, язучы иҗатының төп хасиятләрен, чор әдәбиятының төп үсеш юнәлешләрен билгеләү һәм фикерне исбатлау; әдәби әсәрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә аңлау; әдәби әсәрләрнең тарихи-конкрет һәм гомумкешелек кыйммәтләрен, әдәбияттагы «үтәли» һәм «мәңгелек» проблемаларны ачыклый алу.
- **репродуктив эшчәнлек**: әдәби әсәрнең сюжетын, анда сурәтләнгән вакыйгаларны, характерларны аңлатып бирә, башка әсәрләр белән чагыштыра, бәяли алу; чор әдәбиятына кагылышлы мәгълүматларны гомумиләштереп сөйли алу; төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, энциклопедияләр, электрон чаралар) белән максатчан эшли белү; вакытлы матбугат материалларына мөрәҗәгать итә алу.
- **иҗади эшчәнлек**: төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади, сәнгатьле укый белү; әдәби әсәрләр, язучы иҗаты, чор әдәбияты, гомумән милли әдәбият буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение язу;
- **эзләнү эшчәнлеге**: әдәби әсәргә, язучы иҗатына, чор әдәбиятына, милли әдәбияттагы аерым күренешләргә нисбәтле проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; әсәр белән башка текстлар, шул исәптән башка сәнгать төрләре арасында ассоциатив бәйләнешләрне күрә алу;
- **тикшеренү эшчәнлеге**: тулы текстны анализлау; төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү; әсәрләрне үзара чагыштыру, уртак һәм аермалы якларны таба белү; язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белү; татар, рус (яки башка халыкларның) әдәбиятларында бер төрдәге темага язылган әсәрләрне чагыштыру, милли үзенчәлекләрен ачыклау; татар әдәбиятының рус һәм дөнья әдәбияты мәйданындагы урынын һәм ролен бәяләргә омтылу.

## Уку материалының эчтәлеге
## 10 сыйныф

| № | Бүлекләр исеме | Эчтәлек | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | **Әдәби барыш** | Әдәбият белеме.<br>*Әдәбият тарихы, әдәбият теориясе, әдәби тәнкыйть, традиция, яңачалык,* | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | *дәвамчанлык.*<br>Иҗат юнәлеше, иҗат агымы. Татар әдәбиятының чорларга бүленеше.<br>*Иҗат юнәлешләре: романтизм, реализм, модернизм; иҗат агымнары: мәгърифәтчелек реализмы, тәнкыйди реализм, импрессионизм, сызлану фәлсәфәсе. Татар әдәбиятының чорларга бүленеше.* | |
| 2. | **Борынгы татар әдәбияты (5—12 гас.)** | Гомумтөрки әдәбият. Орхон–Енисей ташъязмалары. | 1 |
| 3. | **Урта гасыр әдәбияты** | Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятындагы өч юнәлеш (дини-дидактик, яңарыш һәм суфичылык). Милли сүз сәнгатенең шәрык әдәбиятына йөз тотып үсү-үзгәрүе, ислам идеологиясенә, фәлсәфәсенә нигезләнүе. Аллаһның берлеген раслаучы дини һәм гадел идарәче, гуманлы шәхесне алга куйган дөньяви мотивларның кушылуы. Әхлакый камил, гадел, гуманлы, сабыр, изге күңелле, эчке һәм тышкы матурлыкка ия шәхес концепциясе. Жанрлар төрлелеге, шәркый жанрларның кулланылыш үзенчәлекләре. | 1 |
| 4. | **Болгар чоры мәдәнияте** | Болгар чоры мәдәнияте (12–13 гас. 1 яртысы). Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы. | 2 |
| 5. | **Алтын Урда чоры мәдәнияте** | Алтын Урда чоры мәдәнияте (13–15 гас. 1 яртысы). С.Сараиның «Гөлестан бит төрки» поэмасы, “Сөһәил вә Гөлдерсен”. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы. | 2 |
| 6. | **Казан ханлыгы чоры мәдәнияте** | Казан ханлыгы чоры мәдәнияте (15 гас.1 яртысы–16 гас.2 яртысы). Кол Шәриф, Мөхәммәдьяр иҗаты. | 1 |
| 7. | **Торгынлык чоры мәдәнияте** | Торгынлык чоры мәдәнияте (16 гас.2 яртысы–19 гас.I яртысы). М.Колый хикмәтләре. Г.У. Имәни иҗаты. | 4 |
| 8. | **Яңарыш чоры әдәбияты** | Яңарыш чоры әдәбияты<br>XIX гасырның беренче яртысы әдәбияты. Г.Кандалый, Акмулла иҗатлары.<br>XIX гасырның икенче яртысы әдәбияты. Мәгърифәтчелек хәрәкәте. Әдәбият мәйданына реализмның килүе, мәгърифәтчелек реализмы, аңа хас төп сыйфатлар, мәгърифәтчелек идеалларының гәүдәләнеше. Әдәби әсәр үзәгендәге гади җир кешесенең милләт язмышы белән үрелеп сурәтләнүе. Аңлы-белемле, мәгърифәтле шәхес концепциясе, аның бирелеш үзенчәлекләре. Сүз сәнгатендә яңа төр һәм жанрларның аерымлануы. Бу чор әдәбиятында төп тема һәм мотивлар буларак аң-белем, мәгърифәт, әхлак, тәрбия. Татар милләтенең уяныргa, үсәргә тиешлеге, хатын-кыз язмышы, алдынгы, бигрәк тә рус | 5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | мәдәниятенә йөз тоту кебек мәсьәләләрнең көнүзәктә торуы. Дөньяви һәм дини мотивларның бирелешендә яңалыклар. Әсәрләрдә төп конфликт буларак искелек һәм яңалык көрәше.<br>Г.Кандалыйның «Бу илләрдә торып калсам...» шигыре. | |
| 9. | **XX йөз башы мәдәнияте**. | XX йөз башы мәдәнияте. XX гасыр башында сүз сәнгатенең үсеш-күтәрелеш чорын кичерүе. Шушы чорда иҗтимагый-сәяси тормышта барган үзгәрешләр, аларның иҗтимагый-сәяси һәм әдәби фикергә йогынтысы, шәрык һәм гареб (көнбатыш) синтезы. Әдәбиятның тормышны реалистик һәм романтик чагылдыру үзенчәлекләре. Заман героена хас сыйфатлар, гыйсъянчы, ялгыз, урталыктагы, үзен милләткә багышлаган яки төшенкелектәге һ.б. төр геройлар. Язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр.<br>Реализмның мәгърифәтчелектән тәнкыйди реализм баскычына күтәрелүе. Сүз сәнгатенең иҗат юнәлешләре, агымнары ягыннан баюы. Модернистик агымнардан импрессионизм, символизм. Милли мәсьәләләрнең активлашуы. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу. Рухи азатлык, иман, гомернең чиклелеге, яшәү һәм үлем, матурлык проблемаларын яңача хәл итү омтылышы.<br>Г.Ибраһимов, Г.Исхакый, Г.Тукай, С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Г.Камал, Ф.Әмирхан, М. Фәйзи, Г.Колахмәтов иҗаты.<br><br>Ф.Кәрими «Аурупа сәяхәтнамәсе» (өзекләр).<br>Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы.<br>Г.Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» тәнкыйть мәкаләсе (өзекләр).<br>Г.Исхакыйның «Көз» повесте, «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте (өзекләр).<br>Г.Тукайның «Өзелгән өмид», «Сәрләүхәсез» шигырьләре.<br>С.Рәмиевның «Мин», «Пәйгамбәр» шигыре.<br>Дәрдемәнднең «Кораб», «Без» шигырьләре.<br>Ф.Әмирханның «Шәфигулла агай» повесте.<br>М. Фәйзинең «Галиябану» драмасы. | 10 |
| 10. | **1920-1930 елларда** | 1920-1930 елларда әдәбиятның каршылыклы үсеше. Романтизм, модернизм (символизм, имажинизм, футуризм һ.б.) иҗат юнәлешләренең әдәби мәйданнан төшерелеп, социалистик реализм агымының төп иҗат методы буларак раслануы. Традицияләрне дәвам итүче әсәрләр. Яңа тормыш төзү хакында сөйләүче әсәрләр. | 8 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | М.Галәү, К.Тинчурин, Г.Рәхим, Һ.Такташ иҗаты.<br>Г.Рәхимнең «Идел» повесте.<br>Һ.Такташның «Җир уллары» трагедиясе. | |
| **Барлыгы:** | | | 35 |

## Уку материалының эчтәлеге
## 11 сыйныф

| № | Бүлекләр исеме | Эчтәлек | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | **Сугыш чоры мәдәнияте**. | Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка тәэсире. Төп тема-проблемалар. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте. М.Җәлил, Ф.Кәрим, Ә.Еники, Ф.Хөсни иҗаты.<br>1. М.Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» циклы.<br>*2.* Ф.Хөснинең «Йөзек кашы» повесте. | 2 |
| 2. | **Сугыштан соңгы чор мәдәнияте** | Сугыштан соңгы чор мәдәнияте (1950–1960 еллар). XX гасырның икенче яртысында “Хрущев җепшеклеге” исемен алган ярымдемократик үзгәрешләрнең сүз сәнгатенә уңай йогынтысы. Х.Туфан, Х.Вахит иҗаты.<br>1. Х.Туфанның «Иртә төшкән кар» шигыре.<br>2. Х.Вахитның «Беренче мәхәббәт» драмасы. | 2 |
| 3. | **1960–80 еллар мәдәнияте.** | Татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Шушы чорда яңа жанрларның, тема-мотивлар, әдәби формаларның аваз салуы. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. Традицияләрнең яңаруы, яңа җәмгыять сыйфатларын эзләү, яңа герой. «Авыл прозасы». Ватан, ил, халык образларының эпик гәүдәләнеше; шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре, гражданлык хисе, халыклар язмышы, кешенең рухи дөньясы, чор кыйммәтләре турында уйлану. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы. Романтизм юнәлешенең яңадан тергезелүе. 1917 еллар инкыйлабына, яңадан төзелгән тормышка бәянең үзгәреш кичерүе. Сугыш темасының үзгә яссылыкта | 10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | куелышы.<br>Ә.Еники, С.Хәким, А.Гыйләҗев, Г.Ахунов, М.Мәһдиев иҗаты.<br>1. Ә.Еникинең «Төнге тамчылар» хикәясе.<br>2. А.Гыйләҗевның «Өч аршын җир» повесте.<br>3. И.Салаховның «Колыма хикәяләре» романы (өзекләр).<br>4. И.Юзеевның «Гашыйклар тавы» драмасы.<br>5. М.Мәһдиевнең «Кеше китә - җыры кала» повесте. | |
| 4. | **1980–2000 еллар мәдәнияте.** | XX-XXI гасыр чигендә татар әдәбиятының тагын бер тапкыр үзгәрүе, яңа дулкын булып күтәрелүе. Үзгәрешләрнең XX гасыр башы татар әдәбиятындагы эзләнүләргә аваздаш булуы. Реализмның типиклаштыруны иҗтимагый–сыйнфый баскычтан гомумкешелек югарылыгына күтәрүе. Совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы ноктасыннан, ил тарихындагы олы этапларның сурәтен тудырган әсәрләр язылу.<br>И.Салахов, Ф.Бәйрәмова, М.Хәбибуллин, Т.Миңнуллин, И.Юзеев, Г.Афзал, Р.Фәйзуллин, М.Әгъләмов, Зөлфәт иҗаты.<br>1. Р.Фәйзуллинның «Нюанслар илендә» циклы.<br>2. Р.Миңнуллинның «Татарларым» поэмасы**.**<br>3. Р. Харисның «Тукайның мәхәббәт төшләре» поэмасы.<br>4. З.Хәкимнең «Гасыр моңы» драмасы. | 10 |
| 5. | **2000—2010 еллар мәдәнияте.** | Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау. Кешенең аңында, аң төпкелендә барган процессларны тергезү. Мифологик, шартлы–символик образларның активлашуы ярдәмендә милли проблематиканы яңа яссылыкта кую, миллилекне тоталитар идеологиягә каршы торучы көч итеп күтәрү.<br>М.Кәбиров, З.Хәким, Р.Зәйдулла иҗаты.<br>1. М.Кәбировның «Мәхәббәттән җырлар кала» повесте.<br>2. Р.Зәйдулланың «Без очарга әзерләнгән идек...», «Соңару» шигырьләре.<br>Дөнья әдәбиятының барышы. Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар.<br>1.Н.Гыйматдинованың «Сихерче» повесте**.** | 10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 2. Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар» повесте. | |
| **Барлыгы:** | | | 34 |

**Тематик планлаштыру**
**10 класс**

| № | Бүлекләр | Дәреснең темасы, эчтәлек элементлары |
|---|---|---|
| **1 нче чирек (8 сәг.)<br>Әдәби барыш - 1 сәг. Борынгы татар әдәбияты (V-XII гасырлар) - 1 сәг. Урта гасыр әдәбияты –1 сәг. Болгар чоры мәдәнияте - 2 сәг. Алтын Урда чоры мәдәнияте -2 сәг. Казан ханлыгы чоры мәдәнияте - 1 сәг.** | | |
| 1. | **Әдәби барыш - 1 сәг.** | *Әдәби барыш. Әдәбият белеме.*<br>*Әдәбият тарихы, әдәбият теориясе, әдәби тәнкыйть, традиция, яңачалык, дәвамчанлык.*<br>*Иҗат юнәлеше, иҗат агымы. Татар әдәбиятының чорларга бүленеше.*<br>*Иҗат юнәлешләре: романтизм, реализм, модернизм; иҗат агымнары: мәгърифәтчелек реализмы, тәнкыйди реализм, импрессионизм, сызлану фәлсәфәсе. Татар әдәбиятының чорларга бүленеше.* |
| 2. | **Борынгы татар әдәбияты (V-XII гасырлар) - 1 сәг.** | Борынгы татар әдәбияты (5—12 гас.)<br>Гомумтөрки әдәбият. Орхон–Енисей ташъязмалары. |
| 3. | **Урта гасыр әдәбияты – 1 сәг.** | Урта гасыр әдәбияты<br>Борынгы һәм урта гасырлар татар әдәбиятындагы өч юнәлеш (дини-дидактик, яңарыш һәм суфичылык). Милли сүз сәнгатенең шәрык әдәбиятына йөз тотып үсү-үзгәрүе, ислам идеологиясенә, фәлсәфәсенә нигезләнүе. Аллаһның берлеген раслаучы дини һәм гадел идарәче, гуманлы шәхесне алга куйган дөньяви мотивларның кушылуы. Әхлакый камил, гадел, гуманлы, сабыр, изге күңелле, эчке һәм тышкы матурлыкка ия шәхес концепциясе. Жанрлар төрлелеге, шәркый жанрларның кулланылыш үзенчәлекләре. |
| 4. | **Болгар чоры мәдәнияте - 2 сәг.** | Болгар чоры әдәбияты (XII-XIII гасырның I яртысы). Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасы.<br>*Идел буе Болгар дәүләте турында сөйләү, дастанның идея-эчтәлеге.* |
| 5. | | “Кыйссаи Йосыф” дастанының сәнгатьчә эшләнеше.<br>*Дастанда камил инсан, нур, кәлям фәлсәфәләре чагылышы; образлар бирелеше,; яңарыш иҗат юнәлеше (Көнчыгыш романтизмы); тропларның кулланылышы, дастанның теле, Урта гасырлар әдәбиятында традиция. Кол Гали образының сәнгатьтә, әдәбиятта чагылышы, Р.Вәлиев һәм М.Галиевнең дәрестән тыш уку өчен* |

| | | |
|---|---|---|
| | | *бирелгән шигырьләренә анализ. "Борынгы Болгарда"шигыре.* |
| 6. | **Алтын Урда чоры мәдәнияте -2 сәг.** | Алтын Урда чоры мәдәнияте (13–15 гас. 1 яртысы). Мәхмүд Болгариның "Нәһҗел-фәрадис" әсәре.<br>*Дини-дидактик иҗат юнәлеше. Харәзми «Мәхәббәтнамә».*<br>Хисам Кятибнең "Җөмҗөмә солтан" дастаны.<br>*Дини-дидактик иҗат юнәлеше.* Котбның "Хөсрәү вә Ширин" поэмасы.<br>*Яңарыш (Көнчыгыш романтизмы) иҗат юнәлеше, дастан җанры.* |
| 7. | | Сәйф Сараи иҗаты. «Гөлестан бит төрки» поэмасы, «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны.<br>*"Гөлестан бит-төрки" әсәренең язылу тарихы, төзелеше, идея-эчтәлеге. «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанының яңарыш (Көнчыгыш романтизмы) иҗат юнәлешендәге әсәр булуы. Образларның хисләрен җиткерүдәге пейзажның роле.* |
| 8. | **Казан ханлыгы чоры мәдәнияте - 1 сәг.** | Казан ханлыгы чоры әдәбияты (XV гасырның I яртысы – XVI гасырның II яртысы). Мөхәммәдьяр иҗаты.<br>*"Нуры содур" поэмасының төзелеше, идея-эчтәлеге, әсәрдә Урта гасырлар төрки-татар әдәбияты традицияләренең чагылышы. «Төхфәи мәрдан» әсәре.*<br>Кол Шәриф иҗаты.<br>*Тормыш юлы; суфичылык иҗат юнәлешенең үзенчәлекләре, парлы суфи символлар, әсәрләренең риторик эндәш формасында һәм газәл жанрында язылуы. "И күңел..."*<br>*Р.Батулланың "Сөембикә" романында Казан ханлыгы чорының чагылышы.*<br>*Тарихи роман, кыйсса; Сөембикә образының бирелеше.* |
| **2 нче чирек (7 сәг.)<br>Торгынлык чоры мәдәнияте - 4 сәг. Яңарыш чоры әдәбияты - 3 сәг.** | | |
| 9. | **Торгынлык чоры мәдәнияте - 4 сәг.** | Торгынлык чоры мәдәнияте (XVI гасырның II яртысы – XIX гасырның I яртысы).<br>*Әсәрләрнең дини-дидактик, суфичылык, яңарыш иҗат юнәлешләрендә язылуы; "Җәмигъ эт-тәварих", "Дәфтәре Чыңгызнамә", "Тәварихе Болгария" хезмәтләре иҗат ителү; сәяхәтнамә жанры һәм Казанда китап басу эше барлыкка килү.* XVI – XIX гасыр әдипләре.<br>*Габди, Габдессәлам, Таҗетдин Ялчыгол, Әбелмәних Каргали, Шәмсетдин Зәки, Һибәтулла Салихов иҗатлары турында мәгълүмат бирү.* |
| 10. | | Мәүла Колый хикмәтләре, аларның идея-эчтәлеге, сәнгатьчә эшләнеше. *"Юмартлык бу күңелне рушан кылыр..."һ.б.хикмәтләре.*<br>*Хикмәт жанры, хикмәтләрнең идея-эчтәлеге, аларның дини-дидактик һәм суфичылык юнәлешендә иҗат ителүе, суфи образлар бирелеше, Мәүла Колый иҗатында традицияләрнең дәвамчанлыгы. "Гыйлемлек хак рәхәттер..." , хикмәтен уку.* |
| 11. | | Габдерәхим Утыз Имәни иҗаты. |

| | | |
|---|---|---|
| | | *Әсәрләренең идея-эчтәлеге, афористик яңгырашы.* “Киңәш”, *”Гыйлемнең өстенлеге турында төркичә бәетләр” әсәрләре.* |
| 12. | | Габдерәхим Утыз Имәни иҗаты. *Әсәрләренең идея-эчтәлеге, афористик яңгырашы “Мөһиммәт әз-заман” поэмасы.*<br>Урта гасырлар төрки-татар әдәбиятын йомгаклау.<br>*Урта гасырлар төрки-татар әдәбиятының чорларга бүленеше; иҗат юнәлешләре; камил инсан, кәлям, нур фәлсәфәләренең суфичылык һәм рационалистик агымның узенчәлекләре. Урта гасырлар төрки-татар әдәбиятында жанрлар: мәдхия, мәрсия.* |
| 13. | **Яңарыш чоры әдәбияты - 3 сәг.** | XIX гасырның беренче яртысы әдәбияты. *Габделҗәббар Кандалый иҗаты.* Тормыш юлы, иҗаты; лирик геройның хис-кичерешләрен чагылдыручы образлар, әлеге образларның фольклорда һәм әдипләр иҗатында кулланылышы; әдәбиятка алып килгән яңалыгы. “Бу илләрдә торып калсам”, “Бу хәсрәтләр бетәр микән” әсәрләре белән танышу. “Сәхибҗәмал” поэмасына анализ. |
| 14. | | Мифтахетдин Акмулланың тормыш юлы, иҗаты.<br>*Әсәрләренең идея-эчтәлеге, образлар бирелеше. “Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе” белән танышу.*<br>Яков Емельяновның тормыш юлы, иҗаты.<br>*Шигырьләре, үзенчәлекләре. “Саранбай”, “Олысымаклык”.* |
| 15. | | XIX гасырның икенче яртысы әдәбияты. Мәгърифәтчелек хәрәкәте. Әдәбият мәйданына реализмның килүе, мәгърифәтчелек реализмы, аңа хас төп сыйфатлар, мәгърифәтчелек идеалларының гәүдәләнеше. Әдәби әсәр үзәгендәге гади җир кешесенең милләт язмышы белән үрелеп сурәтләнүе. Аңлы-белемле, мәгърифәтле шәхес концепциясе, аның бирелеш үзенчәлекләре. Сүз сәнгатендә яңа төр һәм жанрларның аерымлануы. Бу чор әдәбиятында төп тема һәм мотивлар буларак аң-белем, мәгърифәт, әхлак, тәрбия. Татар милләтенең уяныргa, үсәргә тиешлеге, хатын-кыз язмышы, алдынгы, бигрәк тә рус мәдәниятенә йөз тоту кебек мәсьәләләрнең көнүзәктә торуы. Дөньяви һәм дини мотивларның бирелешендә яңалыклар. Әсәрләрдә төп конфликт буларак искелек һәм яңалык көрәше.<br>Дәрестән тыш уку. Ризаэтдин Фәхретдиноның эшчәнлеге. “Әсма, яки гамәл вә җәза” романы.<br>*Роман төшенчәсе, мәгърифәтчелек реализмы, Ризаэтдин Фәхретдиновның галим, укытучы, язучы, публицист, дин әһеле буларак эшчәнлеге.* |
| **3 нче чирек (11 сәг.)**<br>**Яңарыш чоры әдәбияты - 2 сәг. XX йөз башы мәдәнияте -9 сәг.** | | |
| 16. | **Яңарыш чоры әдәбияты – 2 сәг.** | XIX гасырның икенче яртысы әдәбияты . Фатих Кәриминең тормыш юлы.”Аурупа сәяхатнамәсе”.<br>*Әдип, журналист, нәшир Ф.Кәриминең тормыш юлы, күпкырлы эшчәнлеге.* |

| | | |
|---|---|---|
| 17. | | XIX гасырның икенче яртысы әдәбияты Дәрестән тыш уку. Фатих Кәриминең “Морза кызы Фатыйма” хикәясе. *“Морза кызы Фатыйма”хикәясенең идея-эчтәлеге, сәнгатьчә эшләнеше; мәгърифәтчелек реализмы.* “Вакыт инде: без дә торыйк...” (А.Х.Мәхмүтованың шул исемдәге китабыннан очерклар). *XIX гасыр ахыры – XX гасыр башындагы мәгариф, мәдәният үсешенә өлеш керткән хатын-кызлар эшчәнлеге.* Реалистик әдәбият формалашу чорына йомгак. *Мәгърифәтчелек реализмы, әдәбиятның Көнчыгыш һәм Европа мәдәни казанышлары тәэсирендә үсүе төп конфликтның искелек һәм яңалык көрәшендә бирелүе, образлар бирелеше, әдәбиятның төр һәм жанрлар ягыннан да баюы.* |
| 18. | **XX йөз башы мәдәнияте -9 сәг.** | **XX йөз башы мәдәнияте**. XX гасыр башында сүз сәнгатенең үсеш-күтәрелеш чорын кичерүе. Шушы чорда иҗтимагый-сәяси тормышта барган үзгәрешләр, аларның иҗтимагый-сәяси һәм әдәби фикергә йогынтысы, шәрык һәм гареб (көнбатыш) синтезы. Әдәбиятның тормышны реалистик һәм романтик чагылдыру үзенчәлекләре. Заман героена хас сыйфатлар, гыйсъянчы, ялгыз, урталыктагы, үзен милләткә багышлаган яки төшенкелектәге һ.б. төр геройлар. Язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Реализмның мәгърифәтчелектән тәнкыйди реализм баскычына күтәрелүе. Сүз сәнгатенең иҗат юнәлешләре, агымнары ягыннан баюы. Модернистик агымнардан импрессионизм, символизм. Милли мәсьәләләрнең активлашуы. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу. Рухи азатлык, иман, гомернең чиклелеге, яшәү һәм үлем, матурлык проблемаларын яңача хәл итү омтылышы. |
| 19. | | XX гасыр башында әдәби тәнкыйть. Г.Ибраһимов. “Татар шагыйрьләре”. |
| 20. | | Г.Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” әсәрен өйрәнү. *Эчтәлеге белән таныштыру. Романтизмның матур үрнәге булган, социаль психологик роман икщнлеген дәлилләү, әсәрнең фәлсәфи тирәнлеген, көчле психологизмны ачуын һәм, сәнгатьчә эшләнешен анализлап, татар әдәбияты үсешендәге әһәмиятен билгеләү.* |
| 21. | | Г.Исхакый иҗаты. “Ике йөз елдан соң инкыйраз” әсәре. *Әсәрнең идеясен ачыклау, әсәрнең төзелешен, образлар системасын өйрәнү.* |
| 22. | | Г.Исхакыйның “Көз” повесте. Әсәр белән танышу һәм анализ ясау. |
| 23. | | Г.Тукай иҗаты. “Өзелгән өмид”, “Сәрләүхәсез” шигырьләре. *Тормышы , иҗаты һәм эшчәнлеге белән тирәнрәк таныштыру, лирик әсәрләргә анализ.* |
| 24. | | С.Рәмиев иҗаты. *“Мин”, “Пәйгамбәр” Таң вакыты” әсәрләре.* |
| 25. | | Дәрдеменд иҗаты. *“Кораб”, “Без”шигырьләрен анализлау: фикер һәм хис тәңгәллеге, образлар системасы, лирик герой һәм табигать гармониясе; конфликтны тудырган сәбәпләр. “Бүзләрем маналмадым” шигырен өйрәнү. Әсәрне шагыйрьнең иҗаты, фәлсәфи һәм эстетик карашлары яктылыгында бәяләү.* |
| 26. | | Г.Камал иҗаты. |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| **4 чирек (9 сәг.)**<br>**XX йөз башы мәдәнияте -1 сәг. 1920-1930 елларда әдәбият -8 сәг.** | | |
| 27. | **XX йөз башы мәдәнияте -1 сәг.** | Г.Коләхмәтов иҗаты. |
| 28. | **1920-1930 елларда әдәбият -8 сәг.** | **1920-1930 елларда** әдәбиятның каршылыклы үсеше. Романтизм, модернизм (символизм, имажинизм, футуризм һ.б.) иҗат юнәлешләренең әдәби мәйданнан төшерелеп, социалистик реализм агымының төп иҗат методы буларак раслануы. Традицияләрне дәвам итүче әсәрләр. Яңа тормыш төзү хакында сөйләүче әсәрләр. *Иҗтимагый тормыш һәм әдәби хәрәкәт.* Фатих Әмирханның “Шәфигулла агай” повесте.<br>*Революция вакыйгалары тизлегендә төп геройның дөньяга карашы, аңы үзгәрү, фанатизм дәрәҗәсенә җитү, фаҗигагә китерү.* |
| 29. | | Фатих Әмирханның “Шәфигулла агай” повестенә анализ ясау. |
| 30. | | Мирхәйдәр Фәйзинең “Галиябану” драмасы.<br>*Татар драматургиясендә музыкаль драма жанрына нигез салыну; халык тормышын, яшәешен яктырту* |
| 31. | | Гали Рәхимнең тормыш юлы, әдәби-фәнни эшчәнлеге.<br>*Фәнни хезмәтләре турында мәгълүмат бирү, “Татар әдәбияты тарихы” хезмәтенең төзелеше, эчтәлеге, фәндәге әһәмияте турында сөйләү.*<br>Гали Рәхимнең “Идел” повестенда күпкатламлылык.<br>*Төп фикернең сюжет ярдәмендә түгел, фәлсәфи, психологик катлам аша җиткерелүе; психологизм; кеше образларының бирелеше; әсәрдәге күпкатламлылык: фәлсәфи, иҗтимагый, социаль катламнарда бирелгән фикерләр* |
| 32. | | Гали Рәхимнең “Идел” повесте.<br>*Повестьнең конфликты эчке конфликт булуы; символик образларга салынган мәгънә; көчле позиция; эпиграфның мәгънәсе; әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше; кабатлау, янәшәлек, ретроспекция алымнарының кулланылышы; пейзаж; хронотоп бирелеше, сонет, романстагы лирик геройларны Ильяс образы белән чагыштыру.* |
| 33. | | Һади Такташның “Җир уллары трагедиясе” әсәре.<br>*Әсәрнең дини мифология сюжетына нигезләнеп язылуы; ислам легендасында Адәмнең беренче уллары булган Кабил белән Һабил арасындагы конфликтны мәхәббәт һәм ireккә омтылу хисләре белән бәйләп тасвирлау.* |
| 34. | | М.Галәү,  К.Тинчурин иҗатлары. |
| 35. | | Еллык үткәннәрне кабатлау. **Контроль сочинение язу.** |

## 11 класс

| № | Бүлекләр | Дәреснең темасы, эчтәлек элементлары |
|---|---|---|
| **1 нче чирек (9 сәг.)<br>Сугыш чоры мәдәнияте - 2 сәг. Сугыштан соңгы чор мәдәнияте (1950–1960 еллар)- 2 сәг. 1960–80 еллар мәдәнияте – 5 сәг.** | | |
| 1. | **Сугыш чоры мәдәнияте -<br><br>2 сәг.** | Сугыш чоры мәдәнияте. Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка тәэсире. Төп тема-проблемалар. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте. М.Җәлил, Ф.Кәрим, Ә.Еники, Ф.Хөсни иҗаты.<br>М.Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» циклы. |
| 2. | | Фатих Хөсни иҗаты. “Йөзек кашы ”әсәре. “Йөзек кашы” повестена анализ. |
| 3. | **Сугыштан соңгы чор мәдәнияте (1950–1960 еллар)-2 сәг.** | Сугыштан соңгы чор мәдәнияте (1950–1960 еллар). XX гасырның икенче яртысында “Хрущев җепшеклеге” исемен алган ярымдемократик үзгәрешләрнең сүз сәнгатенә уңай йогынтысы. Х.Туфан, Х.Вахит иҗаты.<br>Х.Туфанның «Иртә төшкән кар» шигыре. |
| 4. | | Сугыштан соңгы чор мәдәнияте (1950–1960 еллар). XX гасырның икенче яртысында “Хрущев җепшеклеге” исемен алган ярымдемократик үзгәрешләрнең сүз сәнгатенә уңай йогынтысы.<br>Хәй Вахит иҗаты.”Беренче мәхәббәт” драмасы. |
| 5. | **1960–80 еллар мәдәнияте – 5 сәг.** | 1960–80 еллар мәдәнияте. Татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Шушы чорда яңа жанрларның, тема-мотивлар, әдәби формаларның аваз салуы. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. |
| 6. | | Әмирхан Еники иҗаты. |
| 7. | | Ә.Еники “Төнге тамчылар” хикәясе |
| 8. | | Традицияләрнең яңаруы, яңа җәмгыять сыйфатларын эзләү, яңа герой. «Авыл прозасы». Ватан, ил, халык образларының эпик гәүдәләнеше; шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре, гражданлык хисе, халыклар язмышы, кешенең рухи дөньясы, чор кыйммәтләре турында уйлану. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы. Романтизм юнәлешенең яңадан тергезелүе. 1917 еллар инкыйлабына, яңадан төзелгән тормышка бәянең үзгәреш кичерүе. Сугыш темасының үзгә яссылыкта куелышы. С.Хәким иҗаты. |
| 9. | | А. Гыйләҗев иҗаты. ”Өч аршин җир” повестен уку |
| **2 нче чирек (7 сәг.)<br>1960–80 еллар мәдәнияте – 5 сәг. 1980–2000 еллар мәдәнияте –2 сәг.** | | |

| | | |
|---|---|---|
| 10. | **1960–80 еллар мәдәнияте – 5 сәг.** | А. Гыйләҗев иҗаты ”Өч аршин җир” повестен укуны дәвам итү. Образлар системасы. |
| 11. | | А. Гыйләҗевнең ”Өч аршин җир” повестена анализ ясау. |
| 12. | | Г.Ахунов иҗаты. |
| 13. | | М. Мәһдиев иҗаты. М. Мәһдиевның “Кеше китә- җыры кала” повесте. Романтизм юнәлешенең яңадан тергезелүе. |
| 14. | | М. Мәһдиев иҗаты. М. Мәһдиевның “Кеше китә- җыры кала” повестен укуны дәвам итү |
| 15. | **1980–2000 еллар мәдәнияте –2 сәг.** | 1980–2000 еллар мәдәнияте. XX-XXI гасыр чигендә татар әдәбиятының тагын бер тапкыр үзгәрүе, яңа дулкын булып күтәрелүе. Үзгәрешләрнең XX гасыр башы татар әдәбиятындагы эзләнүләргә аваздаш булуы. Реализмның типиклаштыруны иҗтимагый–сыйнфый баскычтан гомумкешелек югарылыгына күтәрүе. Совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы ноктасыннан, ил тарихындагы олы этапларның сурәтен тудырган әсәрләр язылу.<br>И.Салахов, Ф.Бәйрәмова, М.Хәбибуллин, Т.Миңнуллин, И.Юзеев, Г.Афзал, Р.Фәйзуллин, М.Әгъләмов, Зөлфәт иҗаты. |
| 16. | | И. Салахов иҗаты “Колыма хикәяләре” |
| | **3 нче чирек (10 сәг.)<br>1980–2000 еллар мәдәнияте –8 сәг. 2000—2010 еллар мәдәнияте – 2 сәг.** | |
| 17. | **1980–2000 еллар мәдәнияте –8 сәг.** | Ф. Бәйрәмова иҗаты. “Канатсыз акчарлаклар” повесте. Мотив төшенчәсе |
| 18. | | М.Хәбибуллин, Т.Миңнуллин иҗаты |
| 19. | | И. Юзеев иҗаты. “Гашыйклар тавы” повесть-поэмасын уку |
| 20. | | И. Юзеевның “Гашыйклар тавы” повесть-поэмасында азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы. |
| 21. | | Г.Афзал, М.Әгъләмов иҗаты |
| 22. | | Р. Фәйзуллин иҗаты. «Нюанслар илендә» циклы. “Вәгъдәсезлектән”, “Иртәнге җил” шигырьләрен анализлау. |
| 23. | | Н. Гыйматдинова иҗаты. Нәбирә Гыйматдинованың “Сихерче” әсәрен уку. |
| 24. | | “Сихерче” повестен уку. Сәвилә - архетипик образ. Әсәрне анализлау. |

| | | |
|---|---|---|
| 25. | **2000—2010 еллар мәдәнияте – 2 сәг.** | Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау. Кешенең аңында, аң төпкелендә барган процессларны тергезү. Мифологик, шартлы–символик образларның активлашуы ярдәмендә милли проблематиканы яңа яссылыкта кую, миллилекне тоталитар идеологиягә каршы торучы көч итеп күтәрү. М.Кәбиров, З.Хәким, Р.Зәйдулла иҗаты. |
| 26. | | М. Кәбиров иҗаты. ”Мәхәббәттән җырлар кала” повесте. |
| **4 нче чирек (8 сәг.)**<br>**2000—2010 еллар мәдәнияте – 8 сәг.** | | |
| 27. | **2000—2010 еллар мәдәнияте – 8 сәг.** | М. Кәбиров “Мәхәббәттән җырлар кала” повестен анализлау. |
| 28. | | З. Хәким иҗаты. “Гасыр моңы” театраль романы. |
| 29. | | “Гасыр моңы” театраль романында конфликт, күтәрелгән проблемалар. |
| 30. | | Р. Зәйдулла иҗаты.”Дала җиле”, “Без очарга әзерләнгән идек”, “Йокысызлык”, “Мәһди өне”, «Соңару” шигырьләрен анализлау. |
| 31. | | Р. Харис иҗаты. “Тукайның мәхәббәт төшләре” драматик поэмасы. |
| 32. | | “Тукайның мәхәббәт төшләре” драматик поэмасының теле. Әсәрне анализлау. |
| 33. | | Дөнья әдәбиятының барышы. Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар. Р. Миңнуллин иҗаты. **Оран-поэма төшенчәсе** “Татарларым” оран-поэмасын уку. |
| 34. | | Кабатлау һәм ныгыту. **Контроль сочинение язу** |